Республика Татарстан САРМАНОВСКИЙ МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН СОВЕТ САКЛОВБАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ
ул. Ленина, д. 93 а,
с. Саклов-Баш, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

Татарстан Республикасы САРМАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ САКЛОВ-БАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ
Ленин урамы, 93 а йорт,
Саклов-Баш авылы, 423373.
Телефон: (85559) 4-33-38
E-mail: Sakb.Sar@tatar.ru

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

24.11.2025 г. № 11

«Җир салымы турында» 2020 елның 2 мартындагы 113 номерлы карарга үзгәрешләр кертү хакында

Россия Федерациясе Салым кодексы, «Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 елгы 131-ФЗ номерлы Федераль законның 14 нче статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 елгы 45-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законы, Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының «Саклаубаш авыл җирлеге» муниципаль берәмлеге Уставы, Саклаубаш авыл җирлеге Советы нигезендә карар кылдым:

1. Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районы Саклаубаш авыл җирлеге Советының «җир салымы турында» 2020 елның 2 мартындагы 113 номерлы карарына (Советның 12.10.2020 ел, № 6, 22.02.2023 ел, № 57, 30.10.2023 ел, № 71, 20.01.2025 ел, № 98 карарлары белән кертелгән үзгәрешләр белән) түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

4 пунктка 4.2.2 пунктчасы өстәргә. түбәндәге эчтәлекле:

4.2.2. күпфатирлы йортлар астында урнашкан җир кишәрлекләре өчен торак милекчеләре ширкәтләренә

2. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында халыкка җиткерергә (pravo.tatarstan.ru) һәм Татарстан Республикасы Сарман муниципаль районының рәсми сайтында Интернетны мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә урнаштырырга.

3. Әлеге карар 2025 елның 01 гыйнварыннан, әмма рәсми басылып чыккан көненнән кимендә бер ай узгач үз көченә керә.

4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үземдә калдырам.

Татарстан Республикасы
Сарман муниципаль районы
Саклаубаш авыл җирлеге
Совет рәисе Габидуллина Л.М.